ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 июль 2021 ел № 4940

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 18 апрелендәге 2342 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 18 апрелендәге 2342 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2018 елның 23 гыйнварындагы 251 номерлы, 2021 елның 26 мартындагы 2090 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәдә:

- 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Әлеге нигезләмә белән белән билгеләнгән очракларда гариза бирүчеләргә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган объектларны урнаштыру схемасы белән билгеләнгән урыннарда сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру хокукы бирү электрон аукционнар үткәрү нәтиҗәләре буенча төзелә торган сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга хокук шартнамәсе нигезендә яисә әлеге нигезләмә белән билгеләнгән очракларда сатулар үткәрмичә гамәлгә ашырыла.»;

- 12 пунктның беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Сезонлы кафе Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участогында яки әлеге нигезләмәгә 4 нче кушымта нигезендә билгеләнә торган, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын һәм җәмәгать туклануы объектын урнаштыруга хокукның башлангыч (минималь) бәясенә тигез булган хокук бәясе буенча дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә урнашкан очракта, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать туклануы объектлары карамагында сезонлы кафелар урнаштыру хокукы гариза бирүчегә – җәмәгать туклануы предприятиесе стационар рәвештә урнаштырылган бүлмәләрнең, бинаның, төзелмәнең һәм корылманың хуҗасына яки арендаторына, җәмәгать туклануы объектлары карамагында сезонлы кафелар урнаштыруга шартнамә төзелгәндә, аукцион үткәрмичә бирелә».

- кушымтада каралганча 4 нче кушымта өстәргә;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру хокукына электрон аукцион оештыру һәм үткәрү турында нигезләмәдә 22 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын һәм җәмәгать туклануы объектын урнаштыруга хокукның башлангыч (минималь) бәясен, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын һәм җәмәгать туклануы объектын урнаштыруга хокукның башлангыч (минималь) бәясен билгеләү методикасы нигезендә билгеләргә (Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә 4 нче кушымта)».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 23 июлендәге
4940 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә сезонлы стационар
булмаган сәүдә объектларын һәм
җәмәгать туклануы объектларын
урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын
һәм җәмәгать туклануы объектын урнаштыруга хокукның
башлангыч (минималь) бәясен билгеләү
методикасы

1. Әлеге Методика сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын һәм җәмәгать туклануы объектын урнаштыруга хокукның башлангыч (минималь) бәясен (алга таба - лот) билгеләү максатында эшләнгән.

2. Электрон аукционга куела торган лотның башлангыч (минималь) бәясе дигәндә вәкаләтле орган лотны сатарга әзер булган минималь бәя аңлашыла.

3. Лотның башлангыч (минималь) бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

НЦЛ = (Спкс х Ккс х Кп х Sоб)/12 х Нвр (сум), монда:

НЦЛ - лотның башлангыч бәясе (сум);

Спкс- сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты һәм җәмәгать туклануы объектының мәйданы буенча җир участогы кадастр бәясе күрсәткеченең уртача чагыштырма зурлыгы (сум);

Ккс – җир салымы ставкасы (%) (Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2016 елның 9 ноябрендә 11/6 номерлы карары белән расланган);

Кп - сезонлы стационар булмаган сәүдә объектлары һәм җәмәгать туклануы объектлары (шул исәптән стационар җәмәгать туклануы объектлары карамагындагы) өчен кулланыла торган коэффициент - 80, консервация чорына стационар җәмәгать туклануы объектлары карамагындагы сезонлы объектлар өчен – 10;

Sоб - сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты һәм җәмәгать туклануы объектының мәйданы (кв.м);

Нвр –стационар булмаган сәүдә объекты һәм җәмәгать туклануы объектын урнаштыруның һәр эшчәнлек төре өчен билгеләнгән норматив вакыты (ай).

Сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты һәм җәмәгать туклануы объектын урнаштыруның норматив вакытын бер айдан ким билгеләгәндә, лотның югарыда күрсәтелгән формула буенча исәпләнә торган башлангыч бәясе 30 га бүленергә һәм урнаштыру көннәре санына тапкырланырга тиеш.

Хәрәкәт итү маршрутында мобиль объектларны урнаштыру бәясен билгеләгәндә сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты һәм җәмәгать туклануы объектының мәйданы буенча җир участогы кадастр бәясе күрсәткеченең уртача арифметик зурлыгын файдаланырга кирәк, ул маршрутта барлык урнашу нокталарының Спкс күрсәткечләре

суммасының шул ук маршрутта урнашу нокталары санына чагыштырмасы буларак билгеләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева